# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасының акцизлар турындагы аерым бер закон актларының үз көчләрен югалтуларын тану турында**

1 статья. Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлеше гамәлгә кертелү белән бәйле рәвештә түбәндәгеләр үз көчләрен югалтты дип танырга:

«Акцизлар турында» Татарстан Республикасының 1993 елның 23 мартындагы 1786-XII номерлы Законы (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993 ел, № 3);

«Акцизлар турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү тәртибе хакында» Татарстан Республикасы Югары Советының 1993 елның 23 мартындагы 1787-XII номерлы карары (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993 ел, № 3);

«Акцизлар турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү тәртибе хакында» Татарстан Республикасы Югары Советының 1993 елның 23 мартындагы 1787-XII номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Югары Советының 1993 елның 25 маендагы 1850-XII номерлы карары (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993 ел, № 5).

2 статья. Әлеге Законны рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

3 статья. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты үзенең норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1999 елның 16 ноябре
№ 2426